**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре | № 152-24 | «25» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2021 елның 29 ноябрендәге 56-12 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (25.02.2022 №75-15, 08.06.2023 №133-22 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге №248- Федераль законы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2021 елның 29 ноябрендәге 56-12 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы» нигезләмәгә (25.02.2022 №75-15, 08.06.2023 №133-22 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда контроль чаралар уздыру өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак контроле органы адресына гражданнардан кергән (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек биргән ысул) һәм күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган оешмаларның, дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән алынган мөрәҗәгатьләр санының өч мәртәбә һәм аннан да күбрәк үсеше, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуның фактлары турында дәүләт мәгълүмат системалары хакында.
2. Көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына керү.